Мордовиянен оч кешесе махсус хәрби операциядә катнашучыларга тvләvләрне урлауда шикләнелә, дип хәбәр итәләр Россия Тикшерv комитетынын Мордовия Республикасы буенча Тикшерv идарәсендә.       Тикшерv версиясе буенча, 2025 елда шикләнелvчеләр контракт тозегәндә гражданнарга тиешле акчаларны урлаунын жинаятьчел схемасын эшләгәннәр. Федераль куркынычсызлык хезмәтенен Мордовия Республикасы буенча идарәсе матбугат хезмәтендә анлатуларынча, фигурантлар алдау юлы белән махсус хәрби операциядә катнашучыларнын банк карталарына керv момкинлеге алган. Доресрәге: алданучылар исеменнән милек (имущество) белән идарә итvгә ышанычнамәләр (доверенность) рәсмиләштерv юлы белән.
Законсыз гамәлләр нәтижәсендә СВОнын ике катнашучысына 3,5 млн сумнан артык зыян китерелгән. Тикшерv кысаларында фигурантларнын яшәv урыны буенча тентvләр vткәрелгән, тикшерv очен әһәмияткә ия булган предметлар алынган. Тикшерv тарафыннан алдакчыларга чик кую чарасын сайлау турындагы мәсьәлә хәл ителә. Жинаятьчел эшчәнлек Федераль куркынычсызлык хезмәте һәм Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре белән хезмәттәшлектә, шулай ук Росгвардиянен коче ярдәме белән бу хәл ачыкланган һәм чикләнгән. Хәзерге вакытта тикшерv алып барыла, фигурантларнын, шулай ук жаваплылыкка тартылырга тиешле барлык затларнын хокукка каршы эшчәнлегенен момкин булган башка эпизодлары ачыклана.